| | | |
|---|---|---|
| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 22 сентябрь г.Казань № 1179

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә Татарстан Республикасында транспорт чараларының аерым төрләре мониторингының бердәм системасы турында» 2010 ел, 22 сентябрь, 754 нче карарына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы нигезендә Татарстан Республикасында транспорт чараларының аерым төрләре мониторингының бердәм системасы турында» 2010 ел, 22 сентябрь, 754 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 20 июнь, 397 нче; 2022 ел, 15 август, 829 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

4 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга.

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2006 елга Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнарын мәгълүматлаштыру

өлкәсендә өстенлекле проектлар һәм инфокоммуникация технологияләрен файдалану аудиты нәтиҗәләре турында» 2006 ел, 2 май, 218 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2007 елга Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарында мәгълүмати һәм коммуникация технологияләрен үстерү һәм файдалану буенча өстенлекле проектлар исемлеге турында» 2007 ел, 19 март, 92 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2008 елга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында һәм җирле үзидарә органнарында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен эксплуатацияләү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган өстенлекле проектлар исемлеге турында» 2008 ел, 28 гыйнвар, 39 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 ел, 24 февраль, 94 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының идарәчел карарлар кабул итүенә булышлык күрсәтү буенча мәгълүмат-анализ системасы күрсәткечләре реестры турында» 2010 ел, 3 август, 616 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының идарәчел карарлар кабул итүенә булышлык күрсәтү буенча мәгълүмат-анализ системасы күрсәткечләре реестры турында» 2012 ел, 17 август, 712 нче карарының 1 пунктындагы уникенче – ундүртенче абзацлары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 ел, 30 сентябрь, 701 нче карарының 1 пунктындагы уналтынчы, унҗиденче абзацлары.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин